**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы**
**Сон авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнар җыены карары**
**(КАРАР)**

от «09» ноябрь 2019 г. № 2

**Мамадыш муниципаль районы**
**Сон авыл җирлеге составына керүче**
**Кече Сон авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында»гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 ст., Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең Кече Сон авылында 2019 елның 9 ноябрендә узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең Кече Сон торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Кече Сон торак пунктында Гагарин урамына, Яруллин урамыннан Кече Сон зиратына кадәр юлга вак таш җәю (алып кайту, җәю, килешү буенча түләү);
- Кече Сон авылында Совет урамына балалар мәйданчыгы алып кайтып урнаштыру;
- Кече Сон торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 238 кеше кертелгән;
халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 134 кеше;

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» 134 кеше тавыш бирде;
«Юк» 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең Кече Сон авылында узган халык җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип таныргa.

2. Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең Кече Сон авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип таныргa:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең Кече Сон торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Кече Сон торак пунктында Гагарин урамына, Яруллин урамыннан Кече Сон зиратына кадәр юлга вак таш җәю (алып кайту, җәю, килешү буенча түләү);
- Кече Сон авылында Совет урамына балалар мәйданчыгы алып кайтып урнаштыру;
- Кече Сон торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге
Советы рәисе

М.Ф.Сәләхов

(имза) (имзаның расшифровкасы)